НИК АПТЫРАТАЛАР?..
Хаталы элмә такталарны ачыклау буенча бәйге дәвам итә

> 3

ЯШИСЕ КИЛӘ
Татар гомер буе авыл турында уйлап яши

> 3

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ
«Тезгененңе тыебрак торучы булу – бәхет»

> 4

«АЛ ЯУЛЫК...»
Тинчурин театры «Умай» лабораториясенең нәтиҗәләрен тәкъдим итте

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 95 (28868) | Чәршәмбе | 6 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Торак хуҗалыгы

Татарстан халкы 1 августтан торак-коммуналь хезмәтләр өчен килгән квитанциядә башка бәяләр күрәчәк. 1 июльдән коммуналь хезмәтләр өчен уртача бәя 6,2 процентка артты. Күрше төбәкләр, башка өлкәләр белән чагыштырганда республикада тарифлар түбәнрәк. Бу хакта Министрлар Кабинетында узган брифингта Татарстанның Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе Александр Груничев сөйләде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

СЫЙФАТ ӨЧЕН ТҮЛИСЕ

Җитәкче искәртүенчә, бәяләрнең күтәрелүе – вакыт таләбе. «Бу, беренчедән, хезмәт күрсәтүнең сыйфатын яхшырту өчен кирәк, – ди Груничев. – Әйтик, Татарстанда коммуналь челтәрләрнең 70 проценты тузган. «Водоканал» системасын гына алыйк. Алар инде бик иске. Су торбалары, коммуналь челтәрләр җимерек хәлдә. Аларны яңарту өчен бер генә юл кала – ул да булса, тарифларны күтәреп, шул акчага төзекләндерү эшләрен башлау. Тузган челтәрләрне яңарту эшләрен комитет та контрольдә тотачак».

1 июльдән электр энергиясенә, газ, җылылык, су һәм су түгү, калдыкларны чыгару өчен бәяләр арта. Тарифлар төрле районнарда төрлечә куела. Аларны шул җирлектә хезмәт күрсәтүче оешмалар тәкъдименнән чыгып хәл итәләр. Әйтик, Аксубайда яшәүчеләр суның бер кубометры өчен 19,45 тиен түләсә, азнакайлылар 31,65 сумнарын чыгарып бирергә тиеш булалар. Хәтта бер районда яшәп тә, төрле җирлеккә караган авылда су өчен бәя аерыла. Биектау районының бер җирлегендә су бәясе 19 сум 97 тиен торса, икенче урында 37,58 сумны тәшкил итә.

Александр Груничев аңлатканча, тарифларның төрле булуы җирлеккә хезмәт күрсәтүче оешмаларның икътисади хәленә бәйле. Кайдадыр тарифларны арттырып, биологик чистарту корылмаларын яхшырталар. Кайдадыр халыкка хезмәт күрсәтүче белгечләрнең хезмәт хакына өстиләр.

Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары Алексей Фролов, республикада коммуналь хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын тагын да арттыру кирәк, ди. Аның фикеренчә, фатирларны шәхси җылыту казаны белән тәэмин итү дә үзенең файдалы, кирәкле икәнен раслаган. Республиканың 14 районында йортлар шушы система буенча җылытыла икән.

САН

1 гыйнварда газның бер кубометры 6,07 сум торса, 1 июльдән 6,25 сум булачак. Газ плитәсе өчен шәһәрдә яшәүчеләр элек 4,11 сум түләсә, хәзер 4,30 сум түләячәк.
Электр плитәсе өчен шәһәрдә яшәүчеләр 2,95 сум урынына 3,20 сум, авылда яшәүчеләр элеккеге бәядән 3 тиенгә кыйммәтрәк итеп, 3,01 сумнарын чыгарып бирәчәк.
Эчә торган суның литрына уртача бәя 28,69 тиен булачак. Су түгүнең бер кубометры уртача алганда 26,02 тиен торачак. Чүп чыгарган өчен дә бәя арта. Күпфатирлы йортта яшәүчеләр бер кеше өчен аена – 99,93 сум, үз йортлары белән торучылар аена бер кеше өчен 108,40 сум түли башлый.

– Шәхси казаннар куйдыру кешенең акчасын янга да калдыра. Һәркем үзе теләгәнчә җылыны ача, кирәк икән – сүндерә. Бәяләр арту әлегә артык сизелмәсә дә, кыш көне беленә инде. Җылылык өчен факт буенча түли башлагач, кыш айларында бәя артып китә. Аның каравы җылылык туктатылгач, түләмибез, – ди ул.

Очрашуда 1 августтан түләү квитанциясендә «инвестиционная строка» дигән графа барлыкка киләчәкме дип тә сорадылар. Баксаң, бер очрашуда шундый мәгълүмат җиткергән булганнар икән. Алексей Фролов моны кире какты. «Бу дөрес мәгълүмат түгел, – диде ул. – Без Казанда су һәм су түгү өчен инвестиция программалары кысасында бәяләр арта дигән идек. Бу программалар өчен бәя тарифка кертелгән. Квитанциядә яңа графа булмаячак, борчылырга кирәкми».

Очрашуда Казан халкына хезмәт күрсәтүче «Водоканал» оешмасына төзекләндерү кирәклеге хакында каткат әйтелде. Баксаң, тузган челтәрләр аркасында гына да көн саен 20–22 авария булып тора икән. Сусыз да утырып булмый. Берәр көн су бирми торсалар, бар дөньясын сүгеп, әллә кайларга шалтыратып бетерәбез. Әнә шуңа да җитәкчеләр халыктан җыелган акчага үзләренә файда итәрлек итеп су юлларын төзекләндермәкче булалар.

Тагын шунысы да бар: республикада коммуналь хезмәтләр өчен ташлама алырга мөмкин. Татарстанда июнь аенда гына да бу мөмкинлектән 379237 кеше файдаланган. Кышкы чорда аларның саны тагын да артып китә икән. Ташлама алучылар өчен ел саен аерым бер сумма бирелә. Быел ул 8,6 млрд сумны тәшкил итә. Бу хакта Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары Наталья Бутаева сөйләде.

– Торак-коммуналь хезмәтләр өчен бирелә торган субсидиянең 6,4 млрд сумы – «Хезмәт ветераны» исеме алучыларга, физик мөмкинлеге чикләнгән һәм башка кешеләргә, аз керемле гаиләләр өчен 2,2 млрд сумы тотыла. Хәзерге вакытта республикада авыр хәлдә яшәп, ташлама алучы 100 мең гаилә бар, – ди Наталья Бутаева. – Аз керемле гаиләләр ташлама алыр өчен гаризаны дәүләт порталы аша да тапшыра ала. Әгәр беренче тапшырганда ташлама бирелми икән, гаризаны гел яңартып торырга кирәк. Аны тапшыруда чикләү юк. Электрон мөрәҗәгать белән тизрәк була.

Татарстанда яшәүчеләрнең 60 проценты ташламаны электрон рәвештә рәсмиләштерә икән. Калганнар аны алыр өчен үзләре яшәгән районның социаль яклау бүлегенә мөрәҗәгать итә. Искәртеп үтәбез: бу ташлама Бөек Ватан сугышында катнашучылар, физик мөмкинлеге чикле кешеләр, инвалид бала үстерүче гаиләләр, хезмәт ветераннары, күпбалалы гаиләләр, техноген һәлакәтләрдә зыян күрүчеләргә бирелә. Шулай ук республикада авыр хәлдә яшәгән, матди хәле начар булган гаиләләр дә аннан куллана ала. Ул һәркемнең керемнә карап, аерым исәпләнә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

«Чепья урманы» ядкәре

Татарстанда төбәк әһәмиятендәге махсус сакланылышлы табигый территория булдырылды. Балтач районында «Чепья урманы» табигать ядкәре булдыру турында карарны Премьер-министр Алексей Песошин имзалаган.

«Чепья урманы» төбәк әһәмиятендәге махсус сакланылышлы табигый территориясе 118,9 гектар мәйданны алып тора. Ул нарат, чыршы, ак чыршыны, шулай ук үсемлекләр һәм җәнлекләрне (шул исәптән «Кызыл китап»ка кертелгәннәрен) саклау максатында оештырылган. «Махсус сакланылышлы табигый территория» статусы аның бөтен табигый байлыгын максималь дәрәҗәдә саклап тоту, ау җәнлекләренең үрчүен торгызу, аларның хәлен күзәтеп тору мөмкинлеге бирәчәк.

Акыллыбашлар арта

Быел Татарстаннан 237 укучы Россия күләмендәге олимпиадаларда җиңгән яки призлы урыннар алган. Республика олимпиадалар үзәге директоры Гөлнара Исламова «Реальное время» интернет басмасына әйтүенчә, акыллыбашлар саны узган елдагы белән чагыштырганда 26га арткан. Болар – 25 җиңүче һәм 1 призер. Моннан тыш, 2018 елдагы белән чагыштырганда, Татарстаннан җиңүчеләр саны 98 кешегә ишәйгән. Безнең укучылар быел 10 фән буенча җиңгән яки призлы урыннар яулаган. Үзәк директоры сүзләренә караганда, республика җиңүчеләр һәм призерлар саны буенча, Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсеннән генә калышып, өченче урынга чыккан. Санкт-Петербург – дүртенче. Ә белем сыйфатына килсәк, без – Мәскәүдән соң, икенче.

Узган елда республикадан 211 укучы Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының соңгы этабында призер булган. Бу күрсәткеч буенча республика, Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан гына калышып, Россиядә өченче урынга чыккан.

Үсмерләргә сату тыела

Татарстанда балигъ булмаганнарга хәл кертүче хәмерсез эчемлекләр (энергетиклар) һәм кабызгычлар сатуны тыярга ниятлиләр. «Бердәм Россия» депутатлары бу җәһәттән Дәүләт Советына тиешле закон проектын керткән. Үсмерләргә мондый товар саткан өчен кибетләрне – 150 мең сум, сатучыларны 50 мең сумга кадәр штрафка тарту күздә тотыла.

Депутатлар әйтүенчә, җете этикеткалы эчемлекләр яшьләрдә зур кызыксыну тудыра. Ләкин алар неврологик чирләргә, шул исәптән депрессиягә һәм йөрәк-кан тамырлары авыруларына китерергә мөмкин. Ә инде кабызгычларның тыелган әйберләр исемлегенә эләгү сәбәбе үсмерләрнең кабызгыч газын иснәвенә каршы көрәшүгә бәйле. Республикада шул газны иснәүдән агулану һәм хәтта үлү очраклары бар икән. 2021 елда Чаллыда газ белән агулануның 3 очрагы теркәлгән, быел кышын 13 яшьлек кыз бутан газыннан агуланып үлгән.

Мондый тыюлар Россиянең күп кенә төбәкләренә кертелгән инде. Татарстанда закон проекты көзге сессия барышында каралачак.

Кыздыра башлаячак

Синоптиклар әйтүенчә, атна ахырында республикага эссе, дымлы һава үтеп керәчәк. Термометрның терекөмеш баганасы +32 градуска кадәр күтәреләчәк. Эссе һавага яшенле яңгырлар килеп кушылачак.

Гидрометеоүзәктән хәбәр ителгәнчә, пәнҗешәмбе – 7 июльдә көндез +26...+31 градуска кадәр эсселек көтелә. Төнлә дә җылы: +9...+14 градус. Башлангыч фаразларга караганда, җомга – 8 июльдә һәм ял көннәрендә көндез һава температурасы +27...+32 градус эссе, яшенле яңгырлар булачак.

Сүз уңаеннан, Татарстан урманнарында янгын куркынычы зур булу сәбәпле, 5–11 июль көннәрендә янгыннан кисәтү режимы кертелүен искәртик.

Яңалык

Кермәсеннәр арага

ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫНДА ГАИЛӘ ИНСТИТУТЫН НЫГЫТЫРГА АЛЫНГАННАР

Гаилә хәлләренә сәбәпсез тыкшынмаячаклар. Дәүләт Думасына шул хакта закон проекты кертелде. Документта Гаилә кодексына караган 20 һәм башка норматив актларга кагылышлы 25 төзәтмә бар.

Әлеге үзгәрешләр, хупланган очракта, гаиләләрне эчке эшләренә артык тыкшынудан сакларга, шул рәвешле гаилә институтын ныгытуга ярдәм итәчәк. Аларны әзерләүдә министрлык, ата-аналар комитеты белгечләре дә катнашкан. Закон проектына көзге сессиядә кабат әйләнеп кайтырга җыеналар.

Ә аңа кадәр нәрсә тәкъдим итәргә һәм үзгәртергә җыеналар соң?

Беренчедән, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган очракта (шул исәптән вакытлыча да) туганнарның бала тәрбиясенә хокукы. Моны законда ук беркетергә телиләр. Балага барыбер дә гаиләгә якын булган кешеләрнең назтәрбиясе кадерлерәк инде. Бу очракта туганнар дигәндә кода-кодагыйлар да, исем ата-аналары да һәм башкалар да керә. «Баланы кем тәрбиягә ала?» дигән сорау килеп тугач, аларның өстенлекле хокукы булачак дигән сүз. Бу инде ата-анасыз калган сабыйны теләсә кемгә тапшырырга киртә куячак. Судта да баланы бу кешеләргә бирмәскә дигән карар чыгару өчен саллы дәлилләр таләп ителәчәк.

Тагын бер үзгәреш терминологиягә кагыла. Димәк, гаилә кыйммәтләрен боза торган атамаларга көн бетәчәк. «Беренче номерлы ата-ана», «икенче номерлы ата-ана» дигән кебек сүзләр булмаячак. Баланы тапкан да, баккан да кешеләр ата-ана санала – шуның белән шул.

Шулай ук ата-аналарның баланы тәрбияләү ысулларын сайлау хокукы да законда беркетеләчәк. Тик, билгеле, алар баланың сәламәтлегенә зыян китерүне яисә законнарда тыелган башка гамәлләр кылуны күздә тотарга тиеш түгел.

Тагын бер үзгәреш ата-ананың намуслы булырга тиешлегеннән чыгып кабул ителәчәк (презумпция добросовестности). Ягъни дәүләт, балаларның мәнфәгатьләренә туры китереп, һәм суд намуссызлыкларын карар нигезендә билгеләгәнчегә кадәр, барлык ата-аналарны да гамәлдә дип таныячак.

Сүзгә-сүз

Алексей МАЙОРОВ, Федерация Советының Аграр-азык-төлек сәясәте һәм табигатьтән файдалану комитеты рәисе:

Халык экологик чиста продуктларга аеруча өстенлек бирә. Аларны махсус технологияләр буенча әзерлиләр, нәтиҗәдә бәяләре дә арзан түгел. Шуңа күрә әлеге тауарларны ялганыннан аерырга кирәк. Моңа махсус маркировкалар ярдәмендә ирешеп була.

(«Парламентская газета»)

СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРГӘ КҮПМЕ ВАКЫТ САРЫФ ИТӘСЕЗ?

kp.ru сайты Россиядә яшәүчеләрдән социаль челтәрләргә булган мөнәсәбәтен сорашкан.

36% >> көненә 3–4 сәгать

24% >> бер сәгатьтән дә артмый

16% >> социаль челтәрләрдән башка яши алам

12% >> социаль челтәрләрне даими кулланам



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БӨЛГЕНЛЕК КӨЧӘЙГӘНДӘ

Фәкыйрьлекнең артуы, инфляция, энергетик кризис, фонд базарларының түнтәрелеше… Дөнья илләренең икътисади-социаль тормышын нигездә шул сүзләр белән сурәтләп булыр иде. «Июнь инфляциясе, еллыкка күчереп исәпләгәч, 78,62 процентка җитте», – дип хәбәр итә рәсми төрек статистикасы. Май аенда бу күрсәткеч 73,5 процент булган. Америка компаниясе Bloomberg төрек инфляциясен 79,95 процент дип исәпли. Төрек оппозиционерлары исә тагын да югарырак санны атыйлар. ENAG дип аталган оппозицион оешма матбугат кырына 175,55 процент дигән санны чыгарды. Төрек Хөкүмәте даими рәвештә минималь хезмәт хакын күтәреп, халыкның матди югалтуларын капларга тырыша. Үткән елның декабрендә МРОТ 50 процентка күтәрелгән һәм 2825 лирадан 4250гә җиткән иде. Мартта иң түбән хезмәт хакы күләмен тагын арттырдылар: 4250дән 5500 лирага җиткерделәр. Долларга күчергәч, 327гә тигез. Әмма төрек профсоюзлары конфедерациясе индексация җитәрлек түгел дип шаулый.

Глобаль капитализмның иң бай илләренең берсе булган Германиядә дә фәкыйрьләр саны арта. Халыкның 16,6 проценты хәерчелек чигендә дип санала. Бу – 1990 елдан соң иң югары күрсәткеч. 2020 елдан соң фәкыйрьләр сафына тагын 300 мең тирәсе кеше өстәлгән. Немецлар фәкыйрьлек таралуын пандемия белән бәйлиләр. Вәләкин статистика аз керемлеләр санының 2006 елдан ук даими артуын әйтә. Җитмәсә, Германия икътисады соңгы утыз елда беренче тапкыр айлык сәүдә дефициты белән очрашкан. Экспорт кими, импорт исә 2,7 процентка арткан. Майда сәүдә дефициты 1 миллиард еврога җиткән. Төп сәбәп – Россиягә каршы кертелгән санкцияләр һәм Кытайдагы ковид-чикләүләр.

Россия белән икътисади элемтәләрне өзү нәтиҗәсендә британнар да арзанлы балык ашаудан мәхрүм калганнар. Ак балыкның 30–60 проценты Россиядән китерелгән булган. Британ балыкчылары ул күләмдә балык тотуны арттыра алмыйлар, ди, чөнки ягулык кыйммәт, диңгезгә чыгу икътисади яктан үзен акламый.

Франциядә электр энергиясе биржасында шом көчәя. Бер мегаватт-сәгатькә бәя октябрь – декабрь фьючерсларына 790 еврога җиткән. Бу күрше илләрдәгегә караганда ике-өч тапкыр кыйммәтрәк. Шундый мизгелләр булган: электр бәясе мегаватт-сәгатькә 1500 еврога кадәр җиткән. Германиядә бәя – 500 евро. COVID-кризиска кадәр мегаватт-сәгатьнең бәясе илле евро тирәсе булуын искә алсак, нинди текә күтәрелеш булуын аңларбыз. Француз Хөкүмәте иң күп электр тотучы җитештерүчеләргә энергияне нормалап кына бирүгә күчәргә җыена. Мондый хәл 70 ел булмаган инде.

Быелның беренче яртысы АКШ фонд базары өчен 1970 елдан башлап иң начар чор булган. S&P 500 индексы 21 процент югалткан. Бу – соңгы 50 елның рекорды. Немец индексы DAXта кимен куймаган диярлек: 20 процентка түбәнәйгән. Француз CAC 40 индексының югалтулары – 18 процент.

Криптовалюталар бик нык түбәнгә очтылар. Акчасын биткойнда саклаучы Латин Америкасы илләренең хөкүмәтләре бар. Биткойн белән бергә аларның бюджетлары да упкынга оча. Вакыйгалар һәм фактлар моңарчы күрелмәгән зур кризисның адымнары көчәюе хакында сөйли.

Россиядә

ДӘҮЛӘТ ПРОГРАММАЛАРЫН КИСӘРГӘ

Россия икътисады да дөньякүләм кризистан читтә кала алмый, билгеле. Дөрес, бездә энергия чыганаклары алай ук кыйммәтләнми. Нефть һәм газ бәяләренең глобаль базардагы үсеше безгә файдага гына. Әмма дә ләкин «Газпром» 2021 елга дивидендлар түләүдән баш тартты. Аның бу карары акцияләренең бәясен түбәнгә ташлады. Табигый монополия кәгазьләренең утыз процентка очсызлануы фонд базарын да түнтәрде.

Ихтыяҗның кимүе бәяләр түбәнәюгә китерергә тиеш булса да, Россия базарында икътисадның бу законы кайчак эшләми. Авиакеросинга бәяләр күтәрелү – шуның бер мисалы. Петербург халыкара товар-чимал биржасында 2020 елның апрелендә бер тонна керосин 24 мең сум тирәсе торса, быелның 17 июнендә аның өчен 65,1 мең сум сорыйлар. Бу хәлгә хәтта Монополиягә каршы федераль хезмәт башлыгы Максим Шаскольский да аптырый.

Изоляция хәлендә яшәгән икътисад бюджетны тиешле күләмдә акча белән тәэмин итә алмый. Бюджет профициты бик тиз арада дефицит белән алышынды. Махсус хәрби операциянең бик зур суммаларга төшүе дә сер түгел. Бизнес кичергән кыенлыклар да бюджетта чагылмый калмый. Шул сәбәпле Финанс министрлыгы ил Хөкүмәтенә соңгы елларда беренче тапкыр бюджет секвестры, ягъни казнаның чыгымнар өлешен кисү турында тәкъдим белән чыкты. 2023–2025 еллар бюджетында дәүләт программаларына каралган акча күләмен 1,6 триллион сумга кыскарту күздә тотыла. Транспорт, фән, оборона программаларына каралган акчаны кайчы белән туракларга җыеналар. 2023 елда – 557 миллиард сумны, 2024 елда – 539, 2025 елда 534 миллиард сум акчаны киметү планы инде өстәлгә китереп салынган. Иң күп акчаны «Транспорт системасын үстерү» дәүләт программасы югалтачак. Аннан 390 миллиард сумны алырга җыеналар. «Фәнни-технологик үсеш» дәүләт программасы 150 миллиард сумнан колак кагачак. «Илнең оборонасын тәэмин итү» программасы 120 миллиард сумга кими. Үсеш өчен мөһим булган тармакларның суган суы суырачагын аңлау кыен түгел. Әмма гади халык секвестрны сизмәячәк. Турыдан-туры безнең кесәләргә сукмый бит. Ләкин стратегик югалтулар булып киләчәктә аваз салачак. Белгечләр программаларның пычак астына салынуын вакытлы күренеш дип саный. Бюджетта акча пәйда булу белән финанслау тулысынча кайтарылыр дип өметләнәләр. Тик акчаның кайчан буласы һәм буламы-юкмы икәне мәгълүм түгел. «Дус булмаган» дәүләтләр астыртын басымны һаман да көчәйтәләр. Россиянең алтыны тыю астына килеп эләкте, аны тышкы базарда сату кыенлашачак. Углеводородларга бары тик Россия өчен генә аерым түбән бәя кую планы эшләнә. Россия нефтен һәм газын агымдагы бәянең яртысы күләмендәге акчага гына сатып алуны законлаштырмакчы булалар. Болар тормышка аша калса, бюджет югалтулары тагын да артачак. Югалтуларны тизләтелгән технологик үсеш ярдәмендә генә каплап булыр иде, әмма анысы өчен дә акчаны кисәләр бит әле.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Үзәк хәрби округы гаскәрләре командующие генерал-полковник Александр Лапинга Россия Герое исеме бирелү уңаеннан котлау телеграммасы җибәрде.

«Хөрмәтле Александр Павлович! Сезне Россия Федерациясе Герое исеменә лаек булуыгыз белән эчкерсез котлыйм, – диелә котлауда. – Абруйлы хәрби башлык, хәрби хезмәтнең тәҗрибәле профессионалы буларак, Ватаныбыз өчен катлаулы чорда ватанпәрвәрлегегезне, ил сакчысы дигән бөек исемгә тугрылыгыгызны һәм шәхси батырлыгыгызны тагын бер кат раслап, аеруча әһәмиятле дәүләт бурычын хәл кылуга, илебезнең иминлеген тәэмин итүгә саллы өлеш керттегез. Без, татарстанлылар, Сезнең белән – бөтен гомерен авыр хәрби хезмәткә багышлаган батыр якташыбыз белән горурланабыз, хезмәтегездә яңа уңышлар һәм Россия хакына зур казанышлар телибез! Сезгә һәм гаиләгезгә нык сәламәтлек, тынычлык һәм бәхет насыйп итсен!»

ЧЫКСАҢ, КЕРӘСЕ КИЛМИ

Безнең ишегалды

Быел Татарстанда 1212 ишегалдын төзекләндерәчәкләр. Әлеге эшләр «Безнең ишегалды» программасы кысасында башкарыла.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстан халкы бу программаны куркып кына кабул итсә дә, хәзер аңа әләгүчеләр сөенеп туя алмый. Инде алдан хәбәр иткәнебезчә, әлеге программада күпфатирлы йортлар катнаша. Аларның 2014 елга кадәр төзелгән булуы һәм моңарчы төзекләндерү эшләре башкарылмавы шарт. «Татарстан шәһәрләре үсеше институты» фонды директоры урынбасары, «Безнең ишегалды» программасы координаторы Венера Камалова әйтүенчә, 2020–2021 елларда 2167 ишегалды төзекләндерелгән инде. Бу хакта ул Татарстан Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышында хәбәр итте.

– «Безнең ишегалды» программасы биш елга исәпләнгән. Шушы вакыт эчендә 7 мең ишегалды яңартылачак. Исегезгә төшерәбез: бу – Президент программасы. Аны тормышка ашыру өчен республика бюджетыннан 50 млрд сум акча бүленеп бирелде, – ди ул. – Без ишегалларын анда яшәүчеләр киңәшен истә тотып үзгәртәбез. Һәрдаим алар белән очрашып сөйләшәбез. Уртак фикергә килү өчен бер-беребезгә юл да куябыз. Әмма ни генә эшләсәк тә, без республика халкына ял итәр өчен матур урыннар, аларның яшәгән җирләре чиста, төзек булсын өчен тырышабыз.

Венера Камалова әйтүенчә, ике ел эчендә әлеге программада 890 мең кеше катнашкан. Биш ел эчендә «Безнең ишегалды» программасы 2 миллион кешегә кагылачак.

Дөрестән дә шулай. Казанның Җиңү проспекты, 224б йортында яшәүчеләр дә бу программага бик рәхмәтле. Ишегалдында ремонт эшләре башлангач, күңелләр күтәрелде, ди алар.

– Баштарак бөтен җирне җимереп ташлагач, күңел бераз кителгән иде. Баксаң, эшчеләр эшләрен шулкадәр тиз һәм тәртип белән башкара икән. Шаккатмалы. Берсе казый, икенчесе тигезли. Шул арада юллар салына, тирә-як матурлана. Без моның кадәр үк булыр дип көтмәгән идек. Хәзер ишегалдыннан керәсе дә килми. Бу программа өчен зур рәхмәт, – ди Гөлназ Хәкимова.

«БЕЗНЕҢ ИШЕГАЛДЫ» ПРОГРАММАСЫНДА КАРАЛГАН ЭШЛӘР:



→юл, тротуарлар төзекләндерелә;
→эскәмияләр куела;
→чүп савытлары яңартыла;
→ут яктырткыч баганалар төзекләндерелә яки яңалары куела;
→балаларга уен һәм спорт җиһазлары куела;
→каты көнкүреш калдыклары өчен мәйданчыклар булдырыла яки яңартыла.

Дәвамчыга яхшы нигез

Бик яхшы, эзгә салынган эш. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Кытай Халык Республикасының Казандагы Генераль консулы У Инцин әфәнде белән очрашуда аның дипломат буларак эшчәнлегенә әнә шундый бәя бирде. У Инцин әфәнде Татарстанда үз эшен тәмамлый.

Билгеле булганча, Казанда Кытай Халык Республикасының Генераль консуллыгы 2016 елда ачылды. У Инцинь әфәнде аның беренче Генераль консулы булды. Казандагы консуллыкка Идел буе федераль округының 14 төбәге керә.

«Сез Кытайның Казандагы Генераль консуллыгына нигез салынган көннән бирле эшлисез. Республикабызның иҗтимагый тормышында актив катнашасыз. Беренче Генераль консул буларак сез бу дипломатик эшне бик яхшы эзгә салдыгыз», – диде Фәрит Мөхәммәтшин. Парламент башлыгы бу эшнең яңа Генераль консул килү белән дә дәвам итәчәгенә ышаныч белдерде, У Инцинь әфәндегә исә дипломатик эшчәнлегендә алга таба да уңышлар теләде.

Фәрит Мөхәммәтшин, аңа уртак эше өчен рәхмәт белдереп, Россия белән Кытай арасында ныклы сәүдә-икътисади, гуманитар элемтәләр урнашуын, яхшы эшлекле элемтәләр җайга салынуын да билгеләп үтте. Ике идарә итүче партия – «Бердәм Россия» һәм Кытай Коммунистлар партиясе катнашында күп кенә уртак чаралар уза. Татарстан ике дәүләтнең төбәкара элемтәләрен үстерүгә зур өлеш кертә.

У Инцинь әфәнде, үз чиратында, республика җитәкчелегенә хезмәттәшлек, парламентара элемтәләр кысасында Татарстан белән Кытайның бәйләнешләрен үстерүдә ярдәме өчен рәхмәт белдерде.

«Казанда Кытайның Генконсуллыгын ачу Россия белән Кытай хезмәттәшлегенең төбәкара юнәлешен үстерү өчен яхшы нигез булды. Биш ел эчендә безнең сәүдә-икътисади элемтәләр бик тиз үсеш алды. Киләчәктә хезмәттәшлек итү өчен дә уңай мөмкинлекләр булдырылды», – диде консул. У Инцинь әфәнде Кытай эшмәкәрләренең Россия проектларына инвестицияләр кертү, эшмәкәрлекне үстерү белән бик нык кызыксынуын, илдә һәм, аерым алганда, Татарстанда яхшы инвестицион климат булдырылуын да билгеләп үтте.

Һәркемгә җитәчәк!

Үзебезгә генә түгел, башкаларга да җитәчәк. Әгәр сугару программаларын дөрес башкарабыз икән, Татарстанда яшелчәләргә кытлык булмаячак. Кичә Лаеш районы Нармонка авылында Татарстан Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитетының күчмә утырышында әнә шулай диделәр.

Башта депутатлар «Нармонка» агрофирмасы эшчәнлеге белән танышты. Кырларны карау барышында агрофирма белгечләре килгән кунакларга бәрәңге һәм яшелчә культураларына су сибү системасының өстенлекләре турында сөйләделәр. «Татагролизинг» директоры Азат Җиһаншин сүзләренә караганда, мондый проектның бәясе 1,7 млрд сум тәшкил итә икән. Киләчәктә агрофирма сугарулы җирләрне 1700 гектарга кадәр җиткерергә планлаштыра. Хәзерге вакытта басуларда 18 су сибү агрегаты эшли. Инвестиция программасын гамәлгә ашыру барышында аларның саны 31гә җитәчәк. Хәзерге вакытта җитештерү базасында яшелчә саклау, юу, фасовкалау һәм эшкәртү буенча склад биналары төзү эшләре дәвам итә. Биредә бер үк вакытта 55 мең тоннага кадәр бәрәңге, кәбестә һәм яшелчә сакларга мөмкин булачак.

Очрашуда катнашкан Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, авыл хуҗалыгында сугару эшләрен үстерү мәсьәләләре актуаль булды һәм шулай булып кала, диде.

– Мелиорация – су сиптерү җайланмалары гына түгел, ясалма сугару да, сазлыклы җирләрне киптерү дә, җир эрозиясенә каршы көрәш технологияләре дә, туфракны савыктыру да. Бу – бик мөһим эш. 2010 елның иң көчле корылыгы һәм узган елның түбән уңышы безгә мелиорацияне үстерүнең мөһимлеге турында искәртте. Республикада сугарулы мәйданнар җитәрлек түгел. Шуңа күрә якындагы елларда аларны 50 мең гектарга кадәр арттыру планлаштырыла, – диде ул. – Мелиорациянең максималь нәтиҗәлелегенә ирешү өчен ул алдынгы игенчелек технологияләре белән параллель рәвештә үткәрелергә тиеш. Җирләрне мелиорацияләү программасын уңышлы гамәлгә ашырганда, Татарстан яшелчәләргә ихтыяҗны тәэмин итеп кенә калмыйча, күрше төбәкләргә дә чыга ала.

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Дмитрий Яшин сүзләренчә, республикада мелиорацияне үстерү программасы уңышлы эшләп килә. Соңгы җиде елда Татарстанда җирләрне сугару системасын үстерүгә республика һәм федераль бюджетлардан 6,5 млрд сум акча бүлеп бирелгән. Бу елларда су сибү өчен 200 километрдан артык су торбасы салынган. Шулай ук республика акчасы хисабына сугару җайланмалары өчен тиешле җиһазлар сатып алганда фермерларга ярдәм күрсәтелә. Искеләрен реконструкцияләү һәм яңа гидротехник корылмалар төзү дәвам итә.

САЛАМ ДА КИРӘКМИ, ПЕЧӘН ДӘ

ШӘХСИ ХУҖАЛЫК СЫЕРЛАРЫ ДА «МОНОКОРМ»ГА – ЕЛ ӘЙЛӘНӘСЕ БЕРТӨРЛЕ АШАТУГА КҮЧӘРМЕ?

Авыл сулышы

Бүгенге хуҗалык-җәмгыять сыерлары элекке кебек башак-печән генә ашамый инде. Мөгезеннән койрыгына кадәр сөт эшләүче сыерлар (дөресе шулай, мөгезләрен шул сәбәпле бозау чакта ук көйдерәләр, койрыкларын кисәләр) капиталистик системада элекке гади бер сыер булудан туктап, җитештерү объектына әйләнеп бара. Алардан мөмкин булганча күбрәк сөт алу, басып торган һәр сыерны табышлы итү бурыч та, ихтыяҗ да кебек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Авыл кешеләре арасында да абзарындагы сыерының сөтен арттыру өчен әллә ниләр эшләүчеләр бар. Кемнәрдер, бәясенә карамый, ветаптекалардан өстәмә-кушылмалар сатып ала, безнең тирә-як авылларда күп сыер асраучы кешеләр, мәсәлән, Биектау районына бардага йөри. Берәр тонна сыйдырышлы цистерналар сатып алганнар да, шуны кем «ГАЗель», кем җиңел машина прицебына утыртып, атнага бер тапкыр алып кайталар.

Баксаң, хуҗалыклар әзерләгән «монокорм» – 25әр килограммлы вакуумлы капларга тутырылган махсус ризыкны ашатучы шәхси хуҗалыклар да бар икән.

Балтач районының «Татарстан» хуҗалыгында берничә ел инде заманча терлек азыгы җитештерү үзәге эшли. Үзләрендә булган барлык фермаларга да махсус рацион буенча балансланган азык шушында әзерләнә һәм таратыла. Әлеге үзәктә махсус миксерлар белән әзерләнгән, күптөрле компонентлар кушылган, терлек организмына кирәкле барлык төр микроэлементларга баетылган шушы әзер массаны аерым сатып алучылар өчен уңайлы, вакуумлы капларга тутыра башлауларына да шуның кадәр.

– Моннан ике ел элек ике миллион 900 мең сумга үз акчабызга сатып алган бу җайланманың җитештерүчәнлеге бик югары, көнгә 30 тоннага кадәр азыкны махсус капларга тутыра ала, әлегә авыл халкының күпчелеге элеккечә ашатуны хуп күрә, ә менә бер алган кеше башка районнардан кадәр эзләп килә, – ди хуҗалык рәисе Айнур Нотфуллин. – Үзебездә эшләүчеләргә бер килограммын – унике сумнан, читтән килүчеләргә унөч сумнан сатабыз.

Тәлгать Сәләхов Арча районы Хәсәншәех авылында яши. Үз хуҗалыгында алты сыер асрыйлар.

– Без инде ул ризыкны берничә ел элек Кукмарадан ташып ашаттык, ике ел Балтачка, «Татарстан» хуҗалыгына йөрибез, – ди ул. – Малларны ияләндерергә генә кирәк, аннары бик яратып ашыйлар. Сөткә файдасы бик зур. Сатып алган вакытта кыйммәтрәк кебек тоела, әмма салам, печән, ашлык эзлисе юк, бөтенесен исәпләп карасаң, моннан артыгракка да чыга әле. Җәй көннәрендә көтүгә йөргән сыерларга аны алмыйбыз, хәзерге вакытта ике сыер өйдә тора, аларга шуны ашатабыз. Кышкы чорда исә алты сыерга бер атналык итеп, бер барганда 48 капчык алып кайтабыз. Күршеләребез Рафис Зәкиевләр унтугыз сыер асрый, алар да «Татарстан»га йөри. Алдан шалтыратып заявка бирәсең, түлисең дә алып кайтасың. Бер мәшәкате юк…

Кем белә, шактый гаҗәп кебек тоелса да, тормышын елдан-ел көйләгән, җайлаштырган авыл кешесе, бәлки, тора-бара шушы юлга күчәр. Терлек азыгы туплау да ансат түгел диюем. Хәер, бездә әлегә элекке колхоз системалары сакланып калганга, андый проблема кискен тормый, күрше-тирә районнарда яшәүчеләрне дә ел әйләнәсе ашлык-он белән безнекеләр тәэмин итә. Запас вариант буларак, мондый яңалык көтеп тору да начар түгел ләбаса.

Яңалык димәктән, «Татарстан» хуҗалыгы сыер асраучы шәхси хуҗалыклар өчен ике еллап элек кооператив оештырган икән. Сөтне үзе аша тапшыручылар белән. Безнең җирлектә гомер-гомергә шәхси хуҗалык сөтен колхоз җыйнады. Хәзер дә күпчелек җәмгыятькә тапшыра. Шәхси сөт җыючыларга бирүчеләр дә бар. Берничә сыер асраучылар белән төзелгән кооперативның бер плюсе – сөт өчен хөкүмәт аның әгъзаларына бер литр сөткә бер сум исәбеннән өстәмә түли. Аерма шактый килеп чыга. Башта икеләнеп кенә керсәләр, хәзер теләк белдерүчеләр шактый, инде 45 хуҗалык кооператив әгъзасы булды, диләр. Сөтен саугач, акчасын да мулрак алырга теләү гаеп түгел, юлын күрсәтүләре дә хуплауга лаек.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

ЯШИСЕ КИЛӘ

Ильяс Фәттахов

Авылым тавышлары

Арчаның Шура авылында узган ел булганмын икән, онытканмын, вәт хәтерсез, име! Ярый әле Шураның тиктормас апалары искә төшерде. Мине күрүгә: «Киләсе елга таягымны ташлап киләм, дигән идең, сүзеңдә тормыйсың икән, иптәш Гыйлемханов», – дип көлешеп каршы алдылар. «Аксак кешегә таяк килешә ул», – дип шаярткан булам, үзем уңайсызланам. Чөнки минем корма һәм миннән дә өлкән абый-апалар баскан урыннарында биеп торалар.

Алар – «Чордашлар» этнография ансамбленә йөрүчеләр. Иң яше – Гөлнурга 46 яшь булса, Нәкыйп ага Салихов туксанын тутырырга җыена. Бер уйлаганда, ансамбльгә йөрүче егермегә якын кеше чордашлар да түгел, әмма уй-фикерләре уртак, авылны, татарны яшәтәселәре килә аларның, һәм бу матур сүзләр генә түгел.

Без килгәндә Шура артистлары клуб каршындагы чирәмлектә концерт башлаган иде инде. Көпә-көндез, юк, иртәнге уннар тирәсендә үк авыл уртасында җырласыннар-биесеннәр әле! Барысы да милли киемнәрдән, ут-кызлар инде менә! Үзара «кызлар» дип сөйләшүләре дә кызык булып китте. Бер шаян теллесе: «Әгәр сугышка дисәләр, ун минут эчендә җыелып бетәбез», – диде дә «әстәгъфирулла...» дип укынып куйды. Әйе, бердәм, бик тырыш, үзләре әйтмешли, «мировой проблемалар»ны хәл итәргә кулларыннан килгән кызлар иде болар. Әлбәттә, «мировой» дигәннәре «дөньякүләм» дигән мәгънәдә түгел инде. Сүз шушы авылда, шушы җирлектә хәл ителергә тиешле мәсьәләләр хакында бара, әмма алар татар язмышына кагыла.

«Чордашлар» ансамбленең клуб каршындагы чирәмлеккә җыелуы да табигатьнең матурлыгына мөкиббән китүдән түгел, мәдәният учагы авария хәлендә икән. Ул 1990 елда төзелгән булган. Аны башта мәчет, аннан соң мәктәп булган бинаның бүрәнәләреннән генә корыштырып куйган булганнар. Клуб мөдире Клара Хөсәенова әйтүенчә, инде ике ел буе клубта концерт-фәлән булганы юк икән. «Кеше кертергә шикләнәбез», – ди ул. «Мин кеше түгел...» – дип тозсыз шаяртып, эчкә кердем. Хуҗа кулы сизелә иде монда, хәтта тамаша залының бер почмагында музей да эшләп куйганнар. Монысы да үзенә күрә бер тәрбия чарасы. Тик җир җимертеп эшләргә торган кызлар өчен мөмкинлекләр бик чикле шул монда. Авыл җирлеге башлыгы Әгъзам Гайфуллин әйтүенчә, киләсе елга республика программасы буенча яңа клуб салынырга тиеш, барлык документлары әзер, куллар куелган. Тик Шура артистлары бик тынычланырга теләми. «Ватаным Татарстан» контрольгә алса, тагын да ышанычлырак булыр иде», – диләр. «Ярар, хәбәрләшеп торырбыз», – дигән булдым инде. Әгъзам исә: «Бу апалар, абыйлар белән эшләү күңелле, җыелышларда кайчак ут ягып талашабыз, икенче көнне берни булмагандай йөрибез. Ачу саклау юк», – ди. Шура артистлары исә: «Сезгә шулай бераз әйткәләп тормасаң...» – дип пышылдашып алалар. Бу сүзләрдә ниндидер ачу, үпкә сизмәдем, киресенчә, бергәләп, киңәш-табыш итеп яшәргә ишарә иде бу.

Минем бераз провокаторга әйләнеп аласы килә. «Хәзер клуб нәрсәгә инде ул, анда юньләп йөрүче дә юк», – дигән булам. Шура артистларының хәтере калды һәм: «Клуб авылны да саклый әле ул», – дип үз сүзләрен сүз итәр өчен дәлилләр китерә башладылар. «Ял көннәрендә, җәйге ял вакытларында авылга читтә эшләүче, укучы балаларыбыз, оныкларыбыз кайта. Алар кая барырга тиеш? Кайда аралашырга тиеш?» – диләр. Клубны бердәнбер тәрбия, мәгариф учагы итеп күрә алар.

Баксаң, Шурада мәктәп тә юк икән, балалар күрше Шурабаш авылына йөриләр. Анда исә татар, мари балалары бары тик башлангыч сыйныфларда гына үз ана телләрендә белем ала, шуннан соң урысчага күчәләр икән. Ата-аналарның ихтыяры шундый булган ди. Бүген милли сәясәт әнә шулай гаиләгә йөкләнде. Обидно, кәнишне. Иң кызыгы: Шушмабашта укытучылар – татар. Балалар аңлап бетермәсә, татарчага күчәләр, ди. Әмма урысча тел шомарту дәвам итә һәм татар балалары арасында урыс телендә аңлашучылар арта бара. «Чордашлар»ның бер артисткасы, пенсиядәге укытучы Рәфия Салихова әйтүенчә, клуб милли тәрбия бирүдә дә зур эш башкара ала. «Чордашлар»ны да этнография ансамбле итеп махсус оештырганнар, дәвамчанлык булсын, дигәннәр. Аларның үз телендә сөйләшеп, үз җырын көйләп, үз йола-гадәтләрен саклап, милли хисләрне яшь буынга да сеңдереп яшисе килә. «Чордашлар» артистлары концертларга балаларын, оныкларын да җитәкләп алып киләләр икән дә, тегеләре: «Сез чыннан да шундый җырлар җырлап, шундый уеннар уйнап үстегезме?» – дип авыз ачып, шаккатып утыралар, ди.

Мин «Шура артистлары» дип еш яздым. Чөнки ансамбльгә йөрүчеләр үзләрен универсал саный. «Кирәк икән, спектакльләр дә куя алабыз, теләсә нинди образ тудырырлык артистларыбыз бар», – дип тә җиффәрәләр. Тагын бер кызык нәрсә – ансамбльнең үз мулласы да бар. Бераз шаярткан кебегрәк әйтсәм дә, дөресе шул, ансамбльнең бер баянчысы – Илдар хәзрәт. Аның әйтүенчә, ансамбль кызлары мәчеткә дә йөриләр икән. Ураза вакытында тәравих намазын бер көн дә калдырмаганнар. Дөньяви гамәлләребез әхлак кысасында кылынырга тиеш, дип балаларын-оныкларын да шул рухта тәрбияләргә омтылалар.

Бүген Шурада 240 кеше яши. Дөрес, араларында «үле җан»нар, ягъни монда теркәлеп, читтә яшәүчеләр дә бар. Исәпкә – бар, санга юк булып чыга инде. 14 яшькә кадәргеләр – 13, 14–25 яшьтәгеләр 12 кеше икәнен әйтсәк, киләчәккә өмет бар әле. Әле тагын Шурада яңа клуб ачыласына, анда гөрләп концертлар, спектакльләр узасына да өмет зур.

«Чордашлар» кызлары яңа клубта уйналачак беренче спектакльгә чакырдылар да инде: «Парлап килегез!» – диделәр.

– Әлбәттә, – мәйтәм, – хатын сезнең кебек кызлар янына үземне генә җибәрмәс.

Кызлар моңсу гына елмаешты. Аларның күбесе тол икән инде. Карап торган ике егетләре: Фоат абый белән Нәкыйп абый да – буйдак. Әмма алар ансамбльгә вакыт уздыру, җан тынычлыгы табу өчен генә йөрми. Авылда яшисе, авылны яшәтәсе килә, диләр. Бу сүзләре дә ихлас дип уйлыйм, юкса кайберәүләр бер киткән җиреннән яңадан авылга әйләнеп кайтмаслар иде. Андыйлар Шурада шактый. Клуб мөдире Клара Хөсәенованың юлы тагын да урау булган: Үзбәкстаннан кайткан ул. Кайтыр җирең булмаса, нишләрсең?

Китәр алдыннан беткән бер авыл турында гыйбрәт ишеттем. Анда бүген берәү дә яшәми, ың-шың ишетелми. Әмма йорт нигезләрендә, урамнарда үскән үләннәрне гел чабып, чишмәне карап, зиратны чистартып торалар икән. Кемнәр эше икәнен белмиләр. Татар кендеге авылга, җиргә бәйләнсә дә, кендек бавы кайчак өзелә шул. Әмма татар гомер буе авыл турында уйлап яши сыман. Нинди авыр вакытларда да татар авылларының яшәп калуы шуңа мисал.

Насыйп итсә, шул беткән авыл нигезен күреп кайтам әле. Уйларымны укучыларыма да җиткерермен.

ХАТАЛАР... БЕЗНЕ НИЧЕК АПТЫРАТАЛАР?

«Рыболов» кибетен «Балыкчы» дип тәрҗемә итәргә ярыймы? «Без обеда» сүзтезмәсен «ашсыз һәм төшсез» дип язудан кайчан туктарбыз? Татар телендәге хаталы элмә такталар, топографик билгеләр, юл күрсәткечләре һәм торак йортлар аншлагларындагы исемнәрне барлау буенча бәйге дәвам итә.

Бәйге үзенчәлекләре һәм еш очрый торган хаталар турында Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Бәхтияр Ким улы МИҢНУЛЛИН белән сөйләштек.

:: Бәхтияр Кимович, узган ел бәйгегә тәкъдим ителгән хаталарның бүген күпмесе төзәтелде? Оешма, кибет яки башка орган җитәкчеләре бу мәсьәләгә ни дәрәҗәдә җитди карый? Кайсы районнар һәм шәһәрләр активлык яки, киресенчә, сүлпәнлек күрсәтә?

– Былтыр конкурс кысасында теркәлгән мөрәҗәгатьләрнең күпчелек өлеше хәл ителде. Хәзерге вакытта яңаларын теркәү белән беррәттән, узган елгы хаталарны төзәтү буенча да эш алып барыла. Институт хезмәткәрләре турыдан-туры башкарма комитетлар белән элемтәдә тора. Башкарма комитет хезмәткәрләре әлеге мәсьәләнең җитдилеген аңлап, проблеманы уңай хәл итәргә тырыша. Оешма җитәкчеләре белән нәкъ менә алар эш итә. Тел мәсьәләләренә караган сораулар туган очракта исә институт белгечләре ярдәмгә килә.

Теге яки бу район яисә шәһәрнең активлыгына килгәндә, ул кергән гаризаларның санына бәйле. Шул ук вакытта конкрет бер җирлектән килгән мөрәҗәгатьләр күплеге бу әлеге җирлектәге хәлнең мөшкеллеген күрсәтми. Киресенчә, башка район һәм шәһәрләр белән чагыштырганда, битараф булмаучыларның күбрәк булуын аңлата. Мисал өчен, быел конкурска килгән гаризалар саны буенча лидер булып Казан (1323), Чаллы (451) шәһәрләре, Чистай (719), Яшел Үзән (534), Лениногорск (199), Әлмәт (132), Лаеш (106) районнары тора.

:: Соңгы вакытта халыкның хаталы элмә такталарга карата игътибары арттымы? Арткан икән, бу нидә чагыла? Хата чүпләүчеләр кемнәр: олылармы, яшь буынмы?

– Хәзерге вакытта хаталы элмә такталарны барлау эшендә халыкның активлыгы бермә-бер артты. Бу бүген булган статистик мәгълүматтан да күренә. Мисал өчен, узган елгы конкурста барлыгы 3215 гариза теркәлгән булса, агымдагы бәйгедә 3797 хәбәрнамә теркәлде. Ә бит әле конкурс тагын ике ай дәвам итәчәк!

Хаталарны барлап, конкурста катнашу өчен «Халык контроле» системасына юллаучыларның яшь үзенчәлекләре безгә билгесез, чөнки системада андый мәгълүмат юк.

:: Нинди хаталар еш очрый?

– Иң киң таралган типик хаталар гадәттә сүзләрнең язылышында, сүз тәртибендә, грамматик формаларның кулланышында, аерым сүзләрнең тәрҗемә ителешендә, символларның һәм тыныш билгеләрнең бирелешендә күзәтелә. Моннан тыш аббревиатураларны һәм кыскартуларны дөрес кулланмау очраклары да бар.

Элмә такта текстларының татар телендәге вариантында иң еш очрый торган хаталар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Оешманың куштырнаклар эчендә бирелгән исемен татар теленә тәрҗемә итү. Билгеле булганча, һәр объектның бер генә исеме була ала, аны тәрҗемә итү исә икенче бер исем барлыкка килүгә китерә. Бу исә юридик яктан оешманың эшчәнлегендә кыенлыклар тудырырга мөмкин. Мәсәлән, «Рыболов» кибетенең исеме «Балыкчы» дип татар теленә тәрҗемә ителгән. Ә дөрес вариантта әлеге элмә такта текстының татар вариантында «Рыболов» кибете дип язылырга тиеш, чөнки кибеткә исем рус телендә бирелгән. Татар телендә бирелгән булса, элмә такта текстының рус телендәге вариантында Магазин «Балыкчы», ә татар телендәге вариантта «Балыкчы» кибете дип язарга мөмкин булыр иде.

2. Элмә такта текстларында көн исемнәренең татар телендә бирелешендә дә хаталар күзәтелә. Болар көн исемнәрен дөрес итеп кыскартмауда һәм алардагы татар теленең үзенчәлекле хәрефләренең язылышында чагылыш таба.

3. Оешманың эш вакытын татарча күрсәткәндә рус теле өчен хас булган «с» һәм «до» бәйлекләрен куллану. Элмә такта текстлары татар теленә тулысынча тәрҗемә ителгән очракта да, оешманың эш вакытын күрсәтә торган конструкцияләр ниндидер сәбәпләр аркасында тәрҗемәчеләр игътибарыннан читтә кала. Мондый төр язулар татар телендә түбәндәге формада бирелә: 10.00 нан 19.00 га кадәр, 9.00 дан 18.00 гә кадәр. Шул ук вакытта, әлеге вазгыятьтән чыгуның иң кулай юлы элмә тактаның ике телдәге вариантында да югарыда күрсәтелгән бәйлекләрне төшереп калдыру.

4. Аңлашылмый торган сәбәпләр аркасында күпчелек очракта рус телендәге «без обеда» сүзтезмәсе татар текстында «ашсыз һәм төшсез» дип күрсәтелә. Аны «төшке ашсыз» яисә «төшке ялсыз» дип язарга кирәк.

5. Еш кына «парикмахерская» сүзе татар телендәге элмә такта текстларында парикмахер мәгънәсендәге «чәчтараш», «чәчтарашлык» лексемалары ярдәмендә бирелә. Моннан тыш, әлеге сүзләр хаталар белән языла. Хаталар алда әйтеп үткәнчә, татар теле өчен хас булган үзенчәлекле хәрефләрне бирү белән бәйле.

:: Быелгы бәйге тәртипләрен тагын бер кат искә төшерегез әле. Әле катнашырга соң түгелме?

– Бәйге 1 мартта башланган иде, ул 1 сентябрьгә кадәр дәвам итәчәк. Конкурста катнашу өчен, иң беренче булып, телефонга «Халык контроле» Татарстан дәүләт мәгълүмат системасының (алга таба – «Халык контроле» ТР ДМС) мобиль кушымтасын урнаштырырга кирәк. Аннан «Халык контроле» мобиль кушымтасында (яки Татарстан Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр сайтында, «Халык контроле» ТР ДМС бүлегендә) авторизация үтү, «Исемнәр һәм язуларда хаталар» категориясен сайлау мөһим. Язмаларда төгәл адресны мәҗбүри күрсәтеп, татар телендәге элмә такталар, мәгълүмат такталары, топографик билгеләр, юл күрсәткечләре һәм торак йортлар аншлагларындагы исемнәр һәм язуларда хаталар белән тулы элмә тактаның (аның кайсы оешмага караганлыгы күренергә тиеш) фотоматериаллары белән гариза җибәрү сорала.

Сәрия МИФТАХОВА

Борчыган мәсьәлә

Сез – безгә, без сезгә кирәк

Татарстандагы коммерцияле булмаган оешмалар ни хәлдә? Нинди проблемалары, теләк-тәкъдимнәре бар? Дәүләт аларга ничек ярдәм итә ала? Бу сорауларга җавапны Милли китапханәдә узган утырыш барышында эзләделәр.

vk.com

Утырыш коммерцияле булмаган оешмаларның V республика форумы кысасында узды һәм «Мәдәният өлкәсендәге коммерцияле булмаган оешмалар инициативалары» темасына багышланган иде. Очрашу барышында мөмкинлекләре чикле балалар белән эшчәнлек турында да фикер алыштылар, тәҗрибә уртаклаштылар.

Әлеге очрашуның максат-бурычларын Татарстанның Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Вәлиева атады. «Без монда сезнең теләк-тәкъдимнәрне тыңлар өчен җыелдык. Татарстанның коммерцияле булмаган оешмалар секторын камилләштерү, тагын да югарырак нәтиҗәләргә ирешү өчен шушындый фикер алышулар кирәк. Билгеле, бу өлкәдә республиканың потенциалы зур. Әмма, белгәнегезчә, моны һәрдаим раслап торырга туры килә. Узган елгы нәтиҗәләр буенча, Татарстанның коммерцияле булмаган оешмалар секторы Россия күләмендә өченче урынны алды. Аннан алдагы елда без икенче идек», – диде ул.

Утырышта мәдәният, сәнгать һәм инклюзив өлкәләргә карый торган оешма вәкилләре чыгыш ясады. Татарстанның мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин министрлыкның коммерцияле булмаган оешмалар белән хезмәттәшлеге турында сөйләде. «Мәдәният министрлыгы 60тан артык оешма белән хезмәттәшлек итә. 2021 елда аларга күрсәтелгән матди ярдәм 324,8 млн сумны тәшкил итте. Гомумән алганда, министрлыкның коммерцияле булмаган оешмалар белән хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә күпсанлы һәм иҗтимагый әһәмияткә ия проектлар тормышка ашырылды. Киләчәктә бу өлкәдәге эшчәнлегебезне дәвам итәчәкбез. Ә инде бүгенге очрашу нинди юнәлештә эшләргә кирәклекне тәгаенләргә ярдәм итәр дип уйлыйм», – диде Дамир Натфуллин.

Инде утырышта чыгыш ясаучыларның үзләренә күчик. Араларында тәкъдимнәрен җиткереп кенә калмыйча, тәҗрибә уртаклашучылар да булды. Әйтик, Ваһапов фонды җитәкчесе Рифат Фәттахов грантлар мәсьәләсендә киңәшләрен бирде. «Безнең оешмага дәүләт тарафыннан зур, бик зур ярдәм күрсәтелә. Хәзерге вакытта алты зур проектыбыз дәүләт ярдәме белән тормышка ашырыла. Алар барысы да иҗтимагый, милли әһәмияткә ия», – дип сөйләде ул.

Ул шулай ук проблемалы мәсьәләләргә, аерым алганда, коммерцияле булмаган оешмаларның хокукый статусына кагылышлы сорауларга тукталды. «Коммерцияле оешма булмагач, бизнеска тиешле ярдәмгә дәгъва кыла алмыйбыз. Шул ук вакытта без дәүләт карамагында да түгел. Бу мәсьәләне рәсми төстә хәл итәсе иде», – диде Рифат Фәттахов.

Әйткәнебезчә, очрашуда инклюзия өлкәсе турында да сөйләштеләр. «НеЗаМи» хәйрия фонды химаячесе Дмитрий Бикчентаев мөмкинлекләре чикле балалар белән эшләү тәҗрибәсе турында сөйләде. 120 кв. метрлы 5 бүлмәле бинада 30лап бала белән бик күп төрле инструментларда уйнарга өйрәнә, концертлар, спектакльләр куя, әсәрләр иҗат итә, төрле бәйгеләргә әзерләнә алар. Үзләренең музейлары да бар. «Мондый студия – Россиядә бердәнбер. Чит илләрдә яшәүчеләр дә безгә көнләшеп карый. Чөнки мөмкинлекләре чикле балалар өчен махсуслаштырылган укыту системасы бар. Тик финанслау системасы юк. Җиде укытучыбыз бар. Аларга өч ай буе хезмәт хакы түләнмәде. Яши алсак, Яңа елга кадәр яшәрбез. Ләкин эшебезне дәвам итәсе килә», – дип сөйләде Дмитрий Бикчентаев.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Белдерү

Извещение о необходимости согласования границ земельного участка

Кадастровым инженером Катиным Сергеем Вячеславовичем (аттестат 16-11-169, адрес: 420138, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 51Г, офис 1, тел.: (917) 850-99-44) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:22:040101:8, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Камско-Устьинский район, село Малые Салтыки, улица Чкалова, дом 9, выполняются кадастровые работы по уточнению местоположения границ и площади данного земельного участка.

Заказчик: Хайруллин Фирдус Фаритович (адрес: Респ. Татарстан, Камско-Устьинский район, пгт. Камское Устье, ул. Комарова, д. 17, кв. 11, тел.: +79033418727).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится 10 августа 2022 г. в 09 часов 00 минут по адресу: Республика Татарстан, Камско-Устьинский район, село Малые Салтыки, улица Чкалова, дом 9.

Ознакомиться с проектом межевого плана и предъявить обоснованные возражения относительно местоположения границ земельного участка можно по адресу: 420138, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 51Г, офис 1 в течение 30 (тридцати) дней со дня выхода данного извещения в печать.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ: 16:22:040101:7, 16:22:040101:9, расположены по адресу Республика Татарстан, Камско-Устьинский район, село Малые Салтыки, улица Чкалова, дом 8 и дом 10.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

Язучы фикере



Марат КӘБИРОВ

Макталу теләге

Тезгенеңне тыебрак торучы булу – бәхет. Бәхет ул гел уңайлы булмый.

Мин ихласланып китеп нәрсәдер сөйли башлыйм икән, хатын тезгеннән тарта:

– Марат, мактану кебек ишетелә, – ди. Беләм инде мин аны. Тик нишлим соң инде, зарлана башлыйммыни? Мин дөресен сөйлим. Дөресен әйтәм икән, бу мактану кебек тоела. Аралашуга артык мохтаҗ кеше түгелмен инде, дәшми дә торырга мөмкинмен. Дәшми торсам, эреләнү кебек була. Эндәшсәм – мактанган сыман. Юк, чынлап шулай ул. Минем үз исемемне әйтүем дә мактану кебек тоела. Менә син – Фәлән Фәләнов. Ул – Төгән Төгәнова. Сез бернигә карамыйча, саф намус белән: «Мин – Фәлән Фәләнов, мин – Төгән Төгәнова», – дип кычкырып әйтә аласыз. Хәтта күкрәк суга аласыз. Чөнки сезнең сүзегез дөрес. Күкрәк кагуыгыз да дөрес. Моның өчен сезне беркем гаепли алмый. Ә мин алай итә алмыйм. Әгәр: «Мин – Марат Кәбиров», – дип әйтәм икән, бу мактану булып ишетелә. Күкрәк сукмый гына әйтсәм дә. Гел генә мактанасы килеп тормый инде ул, ә макталасы килә… Мактаулы, данлыклы кеше булу рәхәт.

Бер мәлне «солянка» дип атала торган концертларның берсендә чыгыш ясап төштем дә фойе дип аталган җирдән китеп барам. Тәнәфес инде бу. Мин үзем генә түгел, янымда студент егетләр. Берсеннән-берсе таза, матур. Телохранительләрем шикелле төреп кенә йөртәләр инде мине. Үземнең дә яшь вакыт, мин дә ничава гына. Уфада инде бу. Уфада мин аеруча горур кыяфәт белән йөрим. Чәй эчкән булып китәбез. Мин инде юморист буларак бер-ике кызык сүз әйтеп алам. Таныганнарын, яратканнарын сизеп торам инде. Менә халыкның сиңа нинди мөнәсәбәттә булуы нык сизелә торган әйбер ул. Рәхәт халәт. Шушы халәтне озаккарак сузарга тырышып, юкны бар итеп йөрим инде. Кемдер китап, кемдер түбәтәй яки сувенир бүләк итә. Янымдагы егетләр арасында да рәхәт. Аларның хөрмәтле кешесе бит инде мин, шуңа төреп кенә, урталарында гына йөртәләр. Вәт, мин үз данымның рәхәтен күреп, үз талантыма ләззәтләнеп йөрим.

Ул вакытта кесә телефоннарыннан фотога төшеп булмый иде әле. Танылган кешеләр белән фотога төшәр өчен чиратлар да булмый торган иде. Шунда бер кыз килеп фотога төшәргә тәкъдим итте. Бергәләшеп, кочаклашып төштек. Русча сөйләшә инде үзе. Егете төшерде. Шуннан бер-беребезгә рәхмәт әйтештек тә, мин үз даныма сарылып кына ары атладым. Язучының колагы үткен була, күзәтүчән була. Мин ишетеп торам инде бу парның сөйләшүен. Егете сорый:

– Ә син аның кем икәнен беләсеңме? – ди. Урысча сорый. Шуңа игътибарны алгандыр да инде ул. Һәм кыз да урысча җавап бирә. Ул бүген дә минем колагымда сүзмә-сүз яңгырап тора:

– Да ты че, Коля! Это же сам Салават Фатхетдинов!

Мин тирә-ягыма каранып алдым да иптәш егетләремнең берни сизмәвен тойгач, ишеккә атладым. Теләсә нинди урыннан да данлы вакытыңда чыгып китәргә кирәк бит инде, абруең төшкәнне көтеп ятарга ярамый.

Менә бу үзе үк тезгенне тыю иде.

Соңыннан мин күп нәрсәләрне төшендем. Хәтта исемеңне бутамасалар да, кешеләр сине бертөрле кабул итә, ә син аз гына башкачарак булып чыгасың икән. Кайвакыт юлларың үзеңне яратучыларның максаты белән туры килми. Татарстанга күченеп килгән чакларда янымда бөтерелеп йөрүчеләр шактый гына булды. Тегендә чыгыш ясa, монда әңгәмә үткәр, үзеңне Башкортстанда ничек кысуларын сөйлә. Миңа рәхәт инде бу бер яктан. Үзеңә игътибар биреп, салпы ягыңа салам кыстырып торулары бөтен вакытта да рәхәт була. Мине барысы да белә, ярата, таянычым булырга тели, дип уйлыйсың. Ләкин минем Башкортстанда үземне кысулары, ирек бирмәүләре турында сөйләрлек чутым юк иде. Яхшы язучы булдым мин анда да. Бәйсез, талантлы, бай… Һәрхәлдә, миннән дә ирекләрәк, миннән дә танылганрак, миннән дә баерак язучылар башкорт милләтле чордашларым арасында да юк иде. Эш монда хәтта минем милләтемдә яки сәләтемдә дә түгел иде бугай. Күп эшли торган кеше бит инде мин, төрле өлкәләрдә эшли торган талымсыз кеше. Менә тагын мактану сыманрак яңгырый. Ләкин шундыйрак җавабым басылган бер газетаны Башкортстан матбугаты чиновниклары күтәреп йөрткән: «Менә нинди булырга тиеш ул чын язучы!» – дигәннәр. Бу мактану да, нәрсәгәдер өметләнү дә түгел, ә бары тик ихласлык кына иде. Бер карасаң, алар хаклы инде – чын язучы ихлас булырга тиеш.

Мин сезнең ихлас язучыгыз булдым. Кайчагында әйбәт әйберләр дә яздым. Укучыларым да ихлас булды. Яраттылар. Кайчагында бик үк өнәп тә бетермәделәр. Хаталарым булса, гафу иттеләр. И, беләсезме… Ихласлык ул һәрвакыт гафу ителә.

Мин нәрсәдер язсам, аны иң беренче хатыныма, иң якын күргән кешеләремә тәкъдим итәм инде. Һәм күзләремне мөлдерәтеп төбәп, укып бетерүләрен көтәм. Юл буе ашханәләре янында хуҗасыз этләр була бит… Шулар синең кулыңдагы пирожкига карап дөньяларын оныта. Бер арада күзләреңә төбәлә. И ул күзләрдәге моң! И ул өмет… Мин үземне кайвакыт шундый этләр кебек тоям. Пирожки… Юк, мактау көтәм… Бер үземдә берничә эт була…

Тезгенеңне тыеп торучылар кирәк. Иң якын кешеләрең – шулар. Алар сине хыяллар белән чынбарлык арасын үлчәп карарга мәҗбүр итә. Тезгенеңне тыеп торучы кешең үзең булсаң бигрәк әйбәт. Тик мин алай була алмамдыр кебек…

Мактагыз әле бирәрегез…

«АЛ ЯУЛЫК, ЗӘҢГӘР ШӘЛ…»

ТИНЧУРИН ТЕАТРЫ «УМАЙ» ЛАБОРАТОРИЯСЕНЕҢ НӘТИҖӘЛӘРЕН ТӘКЪДИМ ИТТЕ

Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры үзенең чираттагы сезонын «Умай» лабораториясендә әзерләнгән өч пәрдәлек «Ал яулык, зәңгәр шәл» опера премьерасы белән япты.

«Татар-информ»

«Умай» – татар театры тарихында беренче феминистик лаборатория. Татар мәдәниятендә хатын-кызның тоткан ролен һәм хатын-кызның дөньяга карашын чагылдырган үзенчәлекле лабораториянең эшчәнлек нәтиҗәсе буларак татар телендә өч кыска камера операсы язылган. Әзерләнгән операның барлык авторлары – шагыйрәләр, драматурглар һәм композиторлар – хатын-кызлар. Өч бүлектән торган операның үзәгендә дә – хатын-кыз образы. Опералар татар хатын-кызларының татар мәгърифәтенә һәм тарихи үзгәртеп коруларга керткән өлешенә багышланган. Сюжетлары исә татар мифологиясеннән, җәдитчелек чорындагы татарларның тормыш-көнкүрешеннән алынган. Биредә шулай ук хәзерге заманның көрәшче хатын-кызларының язмышы чагыла.

Опера 20шәр минутлы өч бүлектән тора. Һәр бүлек хатын-кызның язмышына бәйле берәр теманы сурәтли. Монда хатын-кызның җиргә ничек, ни өчен туусы, аны кем, нәрсәдән яралтуы турында сөйләнә. Бүлекләрнең һәркайсын өч төрле автор язган. Операда рольләрне Лилия Мәхмүтова, Зөлфия Вәлиева, Артем Пискунов, Резедә Сәләхова, Айсылу Мөсәлләмова, Илнур Байназаров, Ренат Шәмсетдинов, Венера Низамова башкара.

Пәрдә ачыла һәм без каршыбызда түгәрәк тәрәзәләр уелган диварда милли киемнән Лилия Мәхмүтованы күрәбез. Бу Умай образы булса кирәк. Бераздан түшәмнән кызыл җепкә бәйләнгән ваннага утырган хатын-кыз төшеп утыра – кыз бала туа. Чылбыр өстендә кызыл тасманы кылыч сыман зур пычак белән кисәләр. Бераздан аңа бизәнү әйберләре кидерелә, камчы селтәгән ир каршында ул «минем тәнем хәтерли» дип җырлый.

– Беренче өлешне язганда минем максат – хатын-кызның тәненә куелган табулар һәм таләпләргә игътибарны юнәлтү. Аңа бит тугач ук ниндидер таләпләр куела, килешәсездер. Бу операны күргән кешеләр фикерләрен бераз үзгәртсен, күз йомган нәрсәләрне күрсеннәр иде дигән теләктә калам, – ди беренче либреттоның авторы Миләүшә Гафурова.

Икенче бүлектә ике татар иренә очраклы урыс бер мәйханәдә татар хатынының «череп ятуын», аның баласы да янында булуын сөйли. Ирләрнең берсе бу хакта сәүдәгәр хатыны Фатиха Аитовага җиткерә, ул исә хатынга ярдәм итәргә алына. Аны мунчада юындыралар, киендерәләр, авылына кайтарып куялар. Кызы Әминә Әхмәрова янында кала һәм белем ала. Кечкенә кыз йөзендә хатын-кызның «киләчәкнең ак йөзе» булуы ассызыклана. Шуның белән шул: шәхесләргә кагылып үтсәләр дә, кем алар, нинди эш-гамәлләре белән тарихта калганнар кебек сорауларга җавап табылмады. Гомумән, бу исемнәр фон буларак кына кулланды.

Өченче бүлектә милли мәгариф темасы яктыртыла. Сюжетның герое – куылган укытучы урынына килгән яңа мөгаллимә. Укучылар элеккеге укытучыларының кая китүен, ни өчен куылуын сорыйлар. Артык сораулар биргән сыйныфташына укучылар хор белән: «Сорама, сорашма. Сөйләмә, сөйләшмә», – дип җавап бирә. Зөлфия Вәлиева башкаруындагы яңа укытучы: «…сөйлисеңме-юкмы – үзең сайла. Мин сайладым һәм мин дәшмим генә», – ди. Бу безнең бүгенге көнебезне ачык тасвирлыйдыр кебек.

Премьерадан соң журналистлар һәм кызыксынучылар өчен куючы төркем һәм артистлар катнашында фикер алышу оештырылган иде.

Биюче Нурбәк Батулла тамашада катнашкан актерларга рәхмәт сүзләрен җиткерде.

– Бик зур эш башкаргансыз. Бу – зур батырлык. Опера жанры – ул бик катлаулы юнәлеш, аңа тотынырга махсус уку йортларында укыган кешеләр генә җөрьәт итә ала. Ләкин сез орынгансыз һәм җиңеп чыккансыз дип саныйм. Мин үземне 1906 елдагы беренче театрга килгән кебек хис иттем. Опера жанры безнең милләткә бик туры киләдер кебек. Ул миңа ят бер организм кебек тоелмады. Сез шушы саф жанр аша, акционизмга, эпатажга мөрәҗәгать итмичә, саф формада актуаль теманы күтәрдегез. Бу бик кыйммәт, – диде ул.

Әдәбият белгече Миләүшә Хәбетдинова исә тамашадан канәгать калмавын, бу темаларның безнең өчен актуаль түгеллеген әйтте. Татар хатын-кызы образы ире тарафыннан җәберләнгән, мәйханәләрдә аунап ятучы булырга тиеш түгел, ә гаилә тоткасы, бөек шәхес образын гәүдәләндерергә тиеш дип саный ул.

– Мин бу тамашада татар хатын-кызын күрмәдем. Гомумиләштерелгән татар хатын-кызы образы тудырганда, без җәберләнгән, мәйханәләрдә аунап яткан образларны алырга тиешме? Безнең бит дөнья мәдәниятенә чыгарырлык шәхесләребез бар. Гаилә институтын таркату буенча махсус эш алып барылганда, без татар хатын-кызын гаилә тоткасы образында дөньяга чыгара алабыз. Татар хатыны ирен ир итеп тота белә, аны югары күтәрә, чын ир-ат та хатынына олы хөрмәт күрсәтә, – диде ул.

Җәмәгать эшлеклесе Сүрия Усманова исә, киресенчә, хатын-кызларның җәберләнеп яшәвенең бик актуаль проблема булуын ассызыклады:

– Хатын-кызны җәберләү – бүген бик зур һәм актуаль проблема, аны күтәрергә кирәк. Безнең җәмгыятьтә яшерен проблемалар булырга тиеш түгел, без аларны төрле юллар белән хәл итәргә тиеш. Менә бу юл проблемага игътибарны җәлеп итә.

Либреттога күз салсак, ә аны ишектән керә-керешкә укырга кушалар, биредә хатын-кыз язмышын җитди проблема итеп күтәрү омтылышы бар, әлбәттә. Хатын-кыз образы гаилә учагын гына түгел, бәлки татарны саклаучы милләт анасы образы буларак калка:

«Татар хатын-кызы ул – азатлык, билгесез серле бер көч
һәм рух ныклыгы!
кара безнең милли символларга:
Сөембикә! Ә Алтынчәч! Ә Ашинә!»

Хатын-кыз ярату, илһам, көч чыганагы итеп кенә түгел, гаилә корыда, иҗтимагый тормышта ирләр белән тигез хокуклы шәхес буларак та сурәтләнә.

Тик ни дәрәҗәдә кирәк соң татар театрларына феминистик лабораторияләр? Гади тамашачы мондый опералларга әзерме? Татарстанның атказанган артисты, Тинчурин театры артисты Әлфия Хәсәнова гади тамашачының бу операны аңламаячагын әйтте:

– Бүген бирегә җыелган тамашачы – ул безнең халыкның каймагы. Бу көн саен театрга йөрүче гади тамашачы гына түгел, ә шушы операда куелганны аңларга, уйланырга сәләтле кешеләр. Күрегез, шул кешеләр арасында да никадәр бәхәс купты. Бу операны карарга киләчәк гади тамашачы моңы аңлый алырмы икән? Без уртак фикергә килә алмаганны, гади халык бу тамаша турында ни әйтер?

Ләйсән САФИНА

81 ЯШЬЛЕК ВИТАЛИЙ СЕМЕНОВ:

«МИНЕМ БАКЧАНЫ АМЕРИКАДА ДА БЕЛӘЛӘР»

Балык Бистәсендә яшәүче 81 яшьлек Виталий Семенов капка төбендә үзенчәлекле бакча ясаган. Үзе әйтмешли, ял паркы бу. Телисең икән, таганында атын, тарихи геройлары янына басып фотога төш, кыр чәчәкләре исен иснә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Күпләр аның матурлык тудыруына шаккатса, арада, шайтан туе ясап ятасың, диючеләр дә юк түгел. Үпкәләми бабай, андыйларга җавабы: «Башта үзең шулай эшләп күрсәт әле!»

Ниләр генә юк бакчада! Сөембикә-ханбикә, Алтын Урда сугышчысы, көянтә-чиләкле татар кызы, бакчаны саклап торучы шаман. Соңгы образда якут халкын яратуы чагыла. Барабан кагып торган шаман янәшәсендә йорты, ягъни чумы да бар. Якутларны, ихлас халык, ди. Менә шуңа күрә ясаган да инде. Ул бит әле начар рухларны да якын китерми. Бер-берсенә тугры аккошларны да күрергә мөмкин. Тынычлык күгәрченнәре дә читәнгә кунган. Баганага фонарьлар да куйган, коесын да ясаган. Әнә җил тегермәне аңа яшьлеген, элеккеге тормышны искә төшерә. Киләчәктә «ат җигеп», арба ясап, шуңа ашлык төяп куярга җыена.

– Бу бит Гавай утравы. Мин аны шулай дип йөртәм. Нинди хозурлык! Пальмаларны гына ай буе ясадым. Кыр чәчәкләре үсеп утыра. Бу матурлыкны яшьләр күрсен дип тудырдым. Бакчага бала-чагасы да, өлкәннәр дә керә. Күрше авыллардан да киләләр хәтта. Ял итеп кенә түгел, ишегалдында үскән виноград белән сыйланып та китәләр», – ди киң күңелле Виталий дәдәй.

Үзен ул бик хыялый кеше дип саный. Бу бакчага исә пенсиягә чыккач тотынган. 80 яшькә кадәр эшләп йөргән әле ул! Эш стажы – 45 ел. Хезмәт кенәгәсендә ике генә мөһер сугылган. Берсе – кинофикация, икенчесе – «Сельхозтехника».

– Иң беренче булып арткы бакчага арыш чәчтем. Камыштан зур итеп шалаш кордым. Эсселектән качып, шунда чәй эчеп утыра идек. Арыш көлтәләре бәйләп куйдым. Шуннан соң, башкалар да әлеге матурлыкны күрсен дип, бар хезмәтемне өй каршындагы бакчага чыгардым. Әнә күрәсезме, камышны әле дә үстерәм. Беренче елны өчәр метрлы булып үстеләр хәтта. Көн саен икешәр чиләк су сибеп торам. Таудан агып төшә торган чишмәм бар, тик әле фонтанга һаман вакыт җитми. Читән үрәм, анысы тиз генә эшләнә торган эш түгел. Бер минут та тик тормыйм, һәрвакыт хәрәкәттә мин, – дип илһамланып сөйли Виталий дәдәй.

Менә 20 ел инде Виталий Семенов шушы бакча дип яши. Аны ел саен яңартып, ниндидер үзенчәлекләр өстәп тора. Төннәр буе йокламыйча, планнар корып ята икән. Кызыклы идеяләр күбрәк төнлә туа. Башта авырын, аннан җиңелрәген ясый. Быел Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 77 ел тулу уңаеннан бер почмак булдырган. Истәлекле даталарның берсенә дә битараф түгел ул. Күргәзмәләргә барасы булса, аны да ияртәләр. Элек бөтен иҗатын «Жигули»ена төяп чыгып киткән. Бабайны районда белмәгән кеше сирәктер.

– Бакчаны гел ямьләндереп тору өчен акча да күп китәдер. Хатыныгыз Мария түтәй ачуланмыйммы соң? – дим.

– Акча күп китә шул. Төрле чагы була инде. Чәчәк сабагының бер метры гына да 100 сум бит. Элек агачтан ясый идем. Бала-чага сындырып бетергәч, тимерен сатып ала башладым. Чәчәкләрне пластмасса шешәләрдән ясыйм, аны буйыйм. Бик вак эш бу. Моның өчен сабырлык кирәк. Хатыныма бер эш тә кушмыйм, чөнки барысын да үзем теләгәнчә башкарам. Бу бакчаның дизайнеры үзем, – дип елмая ул.

Виталий дәдәй тумышы белән Балык Бистәсе районының Казаклар Чаллысы авылыннан. Армиядән кайткач, Балык Бистәсенә күченгән. Хатыны Мария белән бергә яши башлавына – 55 ел. Тормыш иптәше аннан сигез яшькә кечерәк. «Булачак хатыным белән Сабантуйда таныштым. Шул көнне үк әнигә: «Бу минем хатын булачак», – дидем. Әни ике тәлинкә, ике кашык бирде. Менә шуннан башланды гаилә тормышы. Бу йортны үз кулларым белән салдым».

Бабай һәр иртәдә сәгать биштә аяк өстендә. Йокыдан торуга балык тотарга китә. Эләксә дә, эләкмәсә дә, йөрергә ияләнгән. Су буйларында йөреп, яңа көч туплап кайта. Иң зур балыгы – 7 килолы. «Көч-хәл белән өстерәп чыгардым. Кармактан ычкынып, кача башлаган иде. Тизрәк өстенә сикердем, тәки тоттым бит. Әле шул балыкны күрсәтеп, урам буенча мактанып йөрдем», – дип кеткелди.

Бакчачылык та – яраткан шөгыле. Виноград үстерү өчен дә ул җаваплы. Сок ясарга да, авыз итәргә дә, башкаларны да сыйларга җитә бу җимеш. Күңелең киң булсын.

– Тормыш мулдан, рәхәт яшибез. Пенсияне вакытында бирәләр, хөкүмәткә рәхмәт. Акчам яхшы. Ике бала тәрбияләгән идек. Бер улыбыз мәрхүм инде. Кызыбыз бар. Оныклар кайта. Менә шулар белән мәш килеп ятабыз, – ди ул.

Кыскасы, зарланып, сукранып ятучы бабай түгел ул. Ул сиңа көн буена җитәрлек көч бирәчәк. Ут борчасы кебек. Әле йөгереп, бакчасының бер почмагына бара, әле икенчесенә. Барысын да күрсәтәсе килә. Җанга рәхәтлек таба ул шушы бакчадан. Иң мөһиме – яшьләр, балалар шушы гүзәллекне күреп үссен дип тырыша. Яшьләргә генә түгел, читтән кайтучыларга да кызык ул. Әнә күршесенә Америкадан кайткан кунак та бабайның эшләренә сокланып, фотоларын интернетка куйган икән. «Минем бакчамны хәзер Америкада да беләләр», – ди ул, сөенеп.

Сәрия МИФТАХОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6640 данә
Гомуми тираж – 16041 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 295

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+